***Муниципаль тур***

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2023-2024 нче уку елы)

**7 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 120 минут**
**Максималь балл – 45**

**1. Татар халык авыз иҗатының кайсы жанры турында сүз баруын языгыз (2 балл):**

- ул халык авыз иҗатының иң кыска жанры;
- ул күчерелмә мәгънәле афористик гыйбарә, хикмәтле сүз дигәнне аңлата;
- сүзне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру вазифасын үти.

**2. Хата белән бирелгән төшенчәләр рәтен күрсәтеп языгыз (2 балл):**

а) йола һәм уен-бию җырлары, тарихи җырлар, лирик озын җырлар, кыска җырлар

ә) сатира, юмор, афоризм, сарказм

б) тарихи җыр, дастан, мөнәҗәт, бәет

**3. Әдипләр портретларын һәм әсәрләргә рәсем-иллюстрацияләрне карагыз.**

**а) Язучыларны һәм аларның әсәрләренә ясалган рәсемнәрне туры китереп билгеләгез (3 балл):**


1) 2) 3)





а) ә) б)





________________________________________________

**ә) Әсәрләрнең авторларын һәм исемнәрен языгыз (3 балл):**

**б) Шул әсәрләрнең берсе турында белгәннәрегезне языгыз (5 балл)**

**4. Персонажларны кайсы әсәрдән алынганлыгын билгеләгез (4 балл):**

1) Хәлвәфрүш а) «Онытылмас еллар»

2) Әхмәдулла ә) «Туган ягым – яшел бишек»

3) Хәлим б) «Кәжүл читек»

4) Гомәр в) «Әбугалисина»

**5. Шигырьдән өзекне укыгыз. Сорауларга җавап языгыз.**

... Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы — моңлы җырчы –
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.
Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңә
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,

Эзе калсын тирән булып,

Үзе үлсә, эше калсын

Мең яшәрлек имән булып.

**а) Әсәрнең исеме (1 балл)**___________

**ә) Әсәрнең авторы (1 балл)**__________

**б) Имән агачын кем утырткан? Ул нинди кеше? (2 балл)** _____________

____________________________________________________________________

**в) Кеше белән имән охшашылыгы нәрсәдә чагылыш таба? (3 балл)**_____

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**г) Шигырьнең төп фикере кайсы юлларда бирелә? Шул юлларны табып языгыз. Сез бу фикер белән килешәсезме? Фикерегезне тормыштан мисаллар белән раслагыз (4 балл)** ____________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

____________________________________________________________________

**6. Терәк сүзләрдән файдаланып, зур булмаган инша языгыз (15 балл)**

*Милли, мәйдан, сабан эшләре, бәйрәм рухы, матур киенгән, күңелле, шат, ярышлар, батыр, чүлмәк, гармун тавышы.*

**Иншагызның текстында әлеге сүзләрнең сайланышы ирекле.**

**Татар әдәбиятыннан мисаллар китерергә онытмагыз.**

**Иншагызга кыска һәм мәгънәле исем бирегез. Иншаның күләме – 8-10 җөмлә.**